**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
УЗЯКСКИЙ СЕЛЬСКИЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

Хазиева ул., д. 8, п. Узяк, 422092
тел. (факс): (84360) 5-22-17,
E-mail: Uzk.Tul@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТЕЛӘЧЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ҮЗӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Хәжиев ур., 8 нчы йорт, Үзәк бистәсе, 422092
тел. (факс): (84360) 5-22-17,
E-mail: Uzk.Tul@tatar.ru

ОКПО 93053615 ОГРН 1061675010165 ИНН/КПП 1619004370/161901001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ
№28**

**КАРАР
«13» август 2020 г.**

**Теләче муниципаль районының Үзәк авыл җирлеге территориясендә дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Президентын һәм Үзәк авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары депутатларын сайлаулар буенча сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннар билгеләү турында**

«2020 елның 13 сентябрендә җирле үзидарәнең вәкиллекле органнары депутатларын сайлауларда сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен һәр сайлау участогы территориясендә махсус урыннар бүлеп бирү һәм җиһазлау турында җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итү хакында» Татарстан Республикасы Теләче районының 2020 елның 28 июлендәге 14/22 номерлы территориаль сайлау комиссиясе карарын карап, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 64 статьясындагы 8 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлеге Башкарма комитеты,

**КАРАР БИРӘ:**

1. Теләче муниципаль районының Үзәк авыл җирлеге территориясендә дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Президентын һәм Үзәк авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары депутатларын сайлаулар буенча сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен түбәндәге махсус урыннарны билгеләргә:

-Үзәк поселогы, Татарстан ур., 7 йорт, авыл җирлеге бинасында мәгълүмат стенды;

- Үзәк п., Хаҗиев ур., шәхси эшмәкәр Хәкимова кибете янында мәгълүмат стенды;

- Шармыш авылы, Мәктәп урамы, шәхси эшмәкәр Хәкимова кибете янында мәгълүмат стенды;

- Сауш авылы, Сиражетдиновлар урамы, шәхси эшмәкәр Гыйлаҗиев кибете янында мәгълүмат стенды;

- Алга авылы, Мерясов урамы, 6 йорт, фельдшер-акушерлык пункты һәм Алга авылы башлангыч мәктәбе бинасында.

2. Үзәк авыл җирлеге башкарма комитетының «Теләче муниципаль районы Үзәк авыл җирлеге территориясендә алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советына депутатлар сайлау буенча сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннар билгеләү турында» 2019 елның 25 июлендәге № 38 карар үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Теләче районы территориаль сайлау комиссиясенә җибәрергә.

4. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

5. Әлеге карарны Үзәк авыл җирлегенең мәгълүмат стендында түбәндәге адрес буенча : Үзәк авылы, Татарстан урамы, 7 йорт, Үзәк авыл җирлеге башкарма комитетының административ бинасында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Теләче муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

Үзәк авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе В.Н.Котников